КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1348

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре

хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче; 2015 ел, 3 октябрь, 739 нчы; 2017 ел, 27 октябрь, 813 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1021 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1269 нчы; 2019 ел, 1 ноябрь, 994 нче; 2020 ел, 15 октябрь, 930 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең бу карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазифа йөкләмәләре күләме саклану һәм алар тарафыннан шул ук квалификация эшләре башкарылу шарты белән, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкәнгә кадәр гамәлдәге хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан ким була алмый.»;

1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеменә бәйле рәвештә билгеләнә торган вазифаи окладлары

1 нче таблица

| Т/с | Хезмәткәрләр вазифалары | Учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркемнәре буенча вазифаи оклад күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Учреждение җитәкчесе (башлыгы) | 34 398 | 28 449 | 26 942 | 25 614 |
| 2. | Учреждениядәге идарә, хезмәт, штаб, үзәк башлыгы | 25 614 | 24 269 | 23 089 | 21 927 |
| 3. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы | 24 269 | 23 089 | 21 927 | 20 845 |
| 4. | Учреждениядәге идарә, хезмәт, штаб, үзәк составындагы бүлек; вәкиллек, мөстәкыйль бүлек (төркем) башлыгы | 23 089 | 21 927 | 20 845 | 19 666 |
| 5. | Бүлек составындагы бүлекчә (төркем) башлыгы | 21 927 | 20 845 | 19 666 | 18 581 |
| 6. | Эзләү-коткару отряды башлыгы | 37 104 | 30 562 | 28 882 | 27 449 |
| 7. | Янгынга каршы хезмәт отряды | 26 942 | 25 614 | 24 269 | 23 089 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | башлыгы | | | | |
| 8. | Янгын часте башлыгы, янгынга каршы хезмәтнең аерым посты | 25 253 | 24 073 | 22 910 | 21 828 |
| 9. | Янгынга каршы хезмәт отряды буенча оператив кизү торучы | 20 647 | 19 566 | 18 565 | 17 648 |
| 10. | Янгынга каршы хезмәт отряды башлыгының матди-техник тәэмин итү буенча ярдәмчесе | 20 845 | 19 666 | 18 581 | 17 584 |
| 11. | Янгынга каршы хезмәтнең җитештерү-техник үзәге, янгынга каршы хезмәтнең укыту үзәге башлыгы | 24 269 | 23 089 | 21 927 | 20 845»; |

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеме нинди булуга карамастан билгеләнә торган вазифаи окладлары

2 нче таблица

| Т/с | Хезмәткәрләр вазифалары | Вазифаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Идарә пункты башлыгы | 19 666 |
| 2. | Учреждение составындагы идарә пункты башлыгы | 17 584 |
| 3. | Химия-радиометрия лабораториясе башлыгы | 19 666 |
| 4. | Уку-укыту һәм методика кабинеты мөдире | 19 666 |
| 5. | Идарәнең оператив кизү торучысы | 17 584 |
| 6. | Идарә пунктының оператив кизү торучысы | 18 581 |
| 7. | Оператив кизү торучының ярдәмчесе | 16 663 |
| 8. | Төп эшчәнлеге буенча инспектор (өлкән инспектор): | |
| | инспектор | 16 663 |
| | өлкән инспектор | 18 581 |
| 9. | Коткаручы: | |
| | халыкара класслы коткаручы | 25 972 |
| | беренче класслы коткаручы | 24 664 |
| | икенче класслы коткаручы | 23 385 |
| | өченче класслы коткаручы | 22 205 |
| | коткаручы | 20 895 |
| 10. | Су астында эшләүче белгеч: | |
| | су астында эшләүче өлкән белгеч | 21 927 |
| | су астында эшләүче белгеч | 20 845 |
| 11. | Гражданнар оборонасы белгече (төп белгеч): | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | төп белгеч | 20 845 |
| | беренче категорияле белгеч | 19 666 |
| | икенче категорияле белгеч | 18 581 |
| | гражданнар оборонасы белгече | 17 584 |
| 12. | Янгын часте каравылы башлыгы, янгынга каршы хезмәтнең аерым посты | 20 483 |
| 13. | Янгынга каршы хезмәтнең күчмә насос станциясе башлыгы | 17 584 |
| 14. | Янгынга каршы хезмәтнең газ һәм су белән сүндерелә торган күчмә җайланма башлыгы | 17 584 |
| 15. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү часте (аерым посты) бүлеге командиры | 19 566 |
| 16. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү частендә газдан һәм төтеннән саклау мастеры | 18 581 |
| 17. | Янгын сүндерү часте (аерым посты) диспетчеры | 16 663 |
| 18. | Янгынга каршы хезмәт (янгын сүндерү часте) отряды инженеры: | |
| | төп инженер | 20 845 |
| | беренче категорияле инженер | 18 581 |
| | икенче категорияле инженер | 17 584 |
| | иженер | 16 663 |
| 19. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын чыгуны профилактикалау инструкторы | 14 992 |
| 20. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерүчесе*: | |
| | беренче класслы янгын сүндерүче | 19 598 |
| | икенче класслы янгын сүндерүче | 18 581 |
| | өченче класслы янгын сүндерүче | 17 665 |
| | янгын сүндерүче | 16 746 |
| 21. | Коткару станциясе башлыгы | 19 666 |
| 22. | Пост (коткару) башлыгы | 15 829 |
| 23. | Маневрлы эзләү төркеме башлыгы | 21 927 |
| 24. | Су астында йөри торган, коткару судносы капитан-механигы | 16 663 |
| 25. | Патруль, коткару катеры капитаны (өлкән моторчы-рулевой) | 14 992 |

*Янгын сүндерүчеләргә класс бирү Учреждение тарафыннан төзелә торган квалификация комиссиясе тарафыннан һәм Учреждение җитәкчесе боерыгы белән расланган нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләре
мөгаллимнәренең вазифаи окладлары

3 нче таблица

| Вазифа исеме | Профессорлар һәм мөгаллимнәр составының гыйльми дәрәҗәсе исәпкә алынган вазифаи окладлары күләме, сум | |
|---|---|---|
| | гыйльми дәрәҗәсе булмаган | фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәсе булган |
| Өлкән мөгаллим | 23 089 | 28 449 |
| Мөгаллим | 20 845 | 25 614»; |

4 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гомумтармак вазифаларын биләүче хезмәткәрләрнең
вазифаи окладлары

4 нче таблица

| Т/с | Хезмәткәрләр категорияләре һәм вазифалары | Вазифаи окладлар, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | Җитәкчеләр | |
| 1. | Канцелярия мөдире: | |
| | документлар әйләнешенең күләме елына 25 мең документка кадәр булганда | 14 242 |
| | документлар әйләнешенең күләме елына 25 мең документтан артыграк булганда | 14 992 |
| 2. | Склад мөдире | 14 992 |
| 3. | Үзәк склад мөдире | 15 829 |
| 4. | Уку-укыту һәм методика кабинеты мөдире | 19 666 |
| 5. | Гараж башлыгы | 20 845 |
| 6. | Радиостанция башлыгы | 18 581 |
| | Белгечләр | |
| 7. | Китапханәче, библиограф: | |
| | төп китапханәче, библиограф | 20 845 |
| | беренче категорияле китапханәче, библиограф | 19 666 |
| | икенче категорияле китапханәче, библиограф | 17 584 |
| | китапханәче, библиограф | 15 829 |
| 8. | Бухгалтер: | |
| | төп бухгалтер | 20 845 |
| | беренче категорияле бухгалтер | 18 581 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | икенче категорияле бухгалтер | 16 663 |
| | бухгалтер | 14 992 |
| 9. | Бухгалтер-ревизор: | |
| | төп бухгалтер-ревизор | 20 845 |
| | беренче категорияле бухгалтер-ревизор | 18 581 |
| | икенче категорияле бухгалтер-ревизор | 17 584 |
| | бухгалтер-ревизор | 16 663 |
| 10. | Эзләү-коткару хезмәтенең гомуми практика табибы | 20 845 |
| | Квалификация категориясе булганда: | |
| | югары категорияле табиб | 24 269 |
| | беренче категорияле табиб | 23 089 |
| | икенче категорияле табиб | 21 927 |
| 11. | Баш белгеч (Учреждение бүлекләрендә, лаборатория-ләрендә, идарәләрендә, хезмәтләрендә, штабларында, үзәкләрендә) | 21 303 |
| 12. | Ашыгыч чакыруларны эшкәртү үзәгенең баш белгече | 21 303 |
| 13. | Диспетчер: | |
| | өлкән диспетчер | 14 992 |
| | диспетчер | 14 242 |
| 14. | Документлар белгече: | |
| | өлкән документлар белгече | 20 845 |
| | беренче категорияле документлар белгече | 18 581 |
| | икенче категорияле документлар белгече | 17 584 |
| | документлар белгече | 15 829 |
| 15. | Инженер (барлык атамалардагы): | |
| | төп инженер | 20 845 |
| | беренче категорияле инженер | 18 581 |
| | икенче категорияле инженер | 17 584 |
| | иженер | 15 829 |
| 16. | Инспекторлар (кадрлар буенча, йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту буенча): | |
| | өлкән инспектор | 14 992 |
| | инспектор | 14 242 |
| 17. | Контракт белән идарә итүче | 19 666 |
| 18. | Корректор: | |
| | өлкән корректор | 17 584 |
| | корректор | 16 663 |
| 19. | Лаборант: | |
| | өлкән лаборант | 14 992 |
| | лаборант | 14 242 |
| 20. | Персонал буенча менеджер | 20 845 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 21. | Механик | 15 829 – 20 845 |
| 22. | Тәрҗемәче: | |
| | төп тәрҗемәче | 20 845 |
| | беренче категорияле тәрҗемәче | 18 581 |
| | икенче категорияле тәрҗемәче | 17 584 |
| | тәрҗемәче | 15 829 |
| 23. | Программист: | |
| | өлкән программист | 23 089 |
| | беренче категорияле программист | 20 845 |
| | икенче категорияле программист | 18 581 |
| | программист | 16 663 |
| 24. | Психолог*: | |
| | төп психолог | 20 845 |
| | беренче категорияле психолог | 19 666 |
| | икенче категорияле психолог | 18 581 |
| | психолог | 17 584 |
| 25. | Җитәкче секретаре | 20 845 |
| 26. | Система администраторы: | |
| | баш система администраторы | 23 089 |
| | төп система администраторы | 20 845 |
| | өлкән система администраторы | 19 666 |
| | система администраторы | 18 581 |
| 27. | Документлар белән тәэмин итү белгече | 19 666 |
| 28. | Белгеч (геомәгълүмат системалары буенча): | |
| | төп белгеч (геомәгълүмат системалары буенча) | 20 845 |
| | белгеч (геомәгълүмат системалары буенча) | 18 581 |
| 29. | Сатып алулар буенча белгеч: | |
| | сатып алулар буенча төп белгеч | 20 845 |
| | сатып алулар буенча өлкән белгеч | 18 581 |
| | сатып алулар буенча белгеч | 15 829 |
| 30. | Кадрлар буенча белгеч | 16 663 |
| 31. | Кадрлар эшее башкару буенча белгеч | 16 663 |
| 32. | Персонал буенча белгеч | 18 581 |
| 33. | Хезмәтне саклау буенча белгеч | 19 666 |
| 34. | Ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгеч: | |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча баш белгеч | 21 303 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча төп белгеч | 19 566 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча өлкән белгеч | 18 565 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча | 17 584 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | белгеч | |
| 35 | Мобилизация эше буенча белгеч | 20 845 |
| 36. | Техник: | |
| | беренче категорияле техник | 15 829 – 17 584 |
| | икенче категорияле техник | 14 992 |
| | техник | 14 242 |
| 37. | Эзләү-коткару хезмәте фельдшеры | 17 584 |
| | Квалификация категориясе булганда: | |
| | югары категорияле фельдшер | 20 845 |
| | беренче категорияле фельдшер | 19 666 |
| | икенче категорияле фельдшер | 18 581 |
| 38. | Рәссам: | |
| | төп рәссам | 20 845 |
| | беренче категорияле рәссам | 18 581 |
| | икенче категорияле рәссам | 17 584 |
| | рәссам | 15 829 |
| 39. | Икътисадчы (барлык атамалардагы): | |
| | төп икътисадчы | 20 845 |
| | беренче категорияле икътисадчы | 18 581 |
| | икенче категорияле икътисадчы | 17 584 |
| | икътисадчы | 15 829 |
| 40. | Юрисконсульт: | |
| | төп юрисконсульт | 20 845 |
| | беренче категорияле юрисконсульт | 18 581 |
| | икенче категорияле юрисконсульт | 17 584 |
| | юрисконсульт | 15 829 |
| | Техник башкаручылар | |
| 41. | Архивариус | 14 242 |
| 42. | Пропускларның дежур бюросы | 13 617 |
| 43. | Кизү торучы (белешмә кәгазьләре бирү, зал, кунакханә каты, ял итү бүлмәсе, тулай торак һ.б. буенча) | 14 242 |
| 44. | Эш башкаручы | 13 927 |
| 45. | Кассир: | |
| | өлкән кассир | 14 242 |
| | кассир | 13 927 |
| 46. | Комендант | 14 992 |
| 47. | Тикшереп үткәрү пункты контролеры | 14 242 |
| 48. | Секретарь | 14 242 |
| 49. | Секретарь-администратор | 18 581 |
| 50. | Секретарь-машинистка: | |
| | беренче категорияле секретарь-машинистка | 14 242 |
| | икенче категорияле секретарь-машинистка | 13 927 |
| 51. | Экспедитор | 13 617 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 52. | Йөкләр ташу буенча экспедитор | 13 927 |

*Гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны бетергәндә ашыгыч ярдәм күрсәтү бурычларын хәл итү өчен билгеләнгән махсус күчмә бүлекчәләр психологларына (биләгән вазифасы нинди булуга карамастан) вазифаи окладлар 20 процентка арттырыла.

Учреждениедә махсус күчмә бүлекчәләрнең булуы Учреждениенең штат расписаниесендә күрсәтелергә тиеш.»;

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшчеләр вазифалары буенча
һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең
тариф ставкалары

5 нче таблица

| Тариф ставкалары төркемнәре | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тарифлар ставкасы күләме, сум | 13 617 | 14 162 | 14 871 | 15 615 | 17 333 | 19 240 | 21 164 | 23 281 | 25 610 – 30 220»; |

14 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

17 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

24 пунктның җиденче абзацында «ялга киткәндә» сүзләрен төшереп калдырырга;

30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. Авыруга һәм озак дәваланырга кирәк булуга, табигый бәла-казага һәм башка нигезле сәбәпләргә бәйле рәвештә матди ярдәм түләү шартлары, аның билгеле бер күләмнәре Учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә. Хезмәткәргә матди ярдәм күрсәтү турында карар Учреждение җитәкчесе тарафыннан хезмәткәрнең язма гаризасы нигезендә кабул ителә.»;

38 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин